“Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Югары Ындырчы авыл җирлегенең Себерче авылында халык җыены нәтиҗәләре һәм 2024 елда үзара салым кертү турында» 2023 елның 15 ноябрендәге 2 номерлы карарын үзгәртү буенча халык җыены нәтиҗәләре турында”

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Югары Ындырчы авыл җирлегенең Себерче авылында
2024 елның 22 мартындагы 2 номерлы халык җыены карары

“Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Югары Ындырчы авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда халык җыенын әзерләү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 10 сентябрендәге 117 номерлы Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Югары Ындырчы авыл җирлеге Советы карарына туры китереп

2024 елның 22 мартында үткән “Сез Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Югары Ындырчы авыл җирлегенең Себерче авылындагы халык җыенының нәтиҗәләре һәм 2024 елда үзара салым кертү турында» карарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча эшләр исемлеге өлешендә үзгәртү һәм 2024 елда алынган үзара салым акчаларын җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге чараларны гамәлгә ашыруга юнәлдерү белән килешәсезме:

- Себерче авылы торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;
- Себерче авылы торак пункт территориясен төзекләндерү

дигән мәсьәлә буенча Себерче авылы халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзеде.

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә буенча:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 9 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 6 кеше .

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда 6 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Югары Ындырчы авыл җирлегенең Себерче авылында халык җыенын узган дип, халык җыенының нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2.Халык җыенында каралган мәсьәлә буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. 2024 елда алынган үзара салым акчаларын җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге чараларны гамәлгә ашыруга юнәлдерергә:

- Себерче авылы торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;
- Себерче авылы торак пункт территориясен төзекләндерү

4.Әлеге карарны мәгълүмат стендындлары аша халыкка белдерергә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Югары Ындырчы авыл җирлеге
Башлыгы Ф.М.Гафиятуллин